СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
КАРАРЫ

**«31» гыйнвар 2017 ел** **№ 98**

**«Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны бер мәртәбә акчалата бүләкләү турында» Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 06 маендагы 272 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Арча район Советы карар бирде:

Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алуга чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бүләкләү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 п.пунктта «15 ел» сүзләрен «тиешле елда дәвамлылыгы әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

*Арча район Советының 2014 елның 6 маендагы 272 номерлы карары белән расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта*

**Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү билгеләү өчен муниципаль хезмәт**
**СТАЖЫ**

| Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү елы | Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажы |
|---|---|
| 2017 | 15 ел 6 ай |
| 2018 | 16 ел |
| 2019 | 16 ел 6 ай |
| 2020 | 17 ел |
| 2021 | 17 ел 6 ай |
| 2022 | 18ел |
| 2023 | 18 ел 6 ай |
| 2024 | 19 ел |
| 2025 | 19 ел 6 ай |
| 2026 һәм аннан соңгы еллар | 20 ел» |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының

законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г.Нуриев